РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«3» октябрь 2024 ел г. Альметьевск № 3220

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 16 маендагы 898 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәгариф идарәсенең мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы 2 өлеше, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 2024 елның 02 августындагы 1381/24 номерлы боерыгы белән «29.03.2022 елның 83/22 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында «Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итүгә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик тәкъдимнәр турында» гы карары нигезендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 16 маендагы 898 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәгариф идарәсенең мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 26 октябрендәге 2465 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның 1 нче кушымтасында:

2 өлешнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.Мәгълүмат-методика бүлеге хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айлык база оклады күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү | аттестацияне уңышлы узган затка квалификация |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | | | программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | бирү белән раслана торган югары һөнәри белем "бакалавр», "магистр" яки " дипломлы белгеч» |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 18 405,00 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 18 410,00 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлек структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) урынбасары; | - | - | 18 481,00 |
| | муниципаль берәмлекләр педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә | - | - | 18 550,00 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | ашыручы бүлек структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) | | | |

5 бүлекнең 3.3 пунктын унынчы абзацында «өстәмәләр күләме» сүзләреннән соң «Мәгарифтәге казанышлар өчен» күкрәк тамгасын, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклап калу һәм үстерү өчен» күкрәк билгесен, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесен, «Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» билгесен, «Мактаулы остаз» мактау билгесен» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта “Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы)” бүлегендә “Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Советлар Социалистик Республикалары берлегенең, Россия Советлар Федератив Социалистик Республикасының ведомство (тармак) бүләкләре, аларның булу өчен стимуллаштыра торган характердагы түләүләр бирелә торган” бүлегендә 1 нче кушымтада Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Мәгариф идарәсенең мәгълүмати-методик бүлеге хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә 1.8.,1.9.,1.10.,1.11. түбәндәге эчтәлекле пунктчалар өстәргә:

| | |
|---|---|
| 1.8. | Россия Федерациясе мәгариф өлкәсенең Мактаулы хезмәткәре |
| 1.9. | Балаларны һәм яшьләрен тәрбияләү өлкәсендә Россия Федерациясе Мактаулы хезмәткәре |
| 1.10. | Мәгариф отличнигы |
| 1.11. | Тәрбия һәм белем бирүдә Россия Федерациясенең Мактаулы хезмәткәрләре |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — А.М. Каюмов